# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның «28» октябреннән № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 26 октябрендә 11.00 сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылы Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә сез, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш; Россия Федерациясе Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләре, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары; 85 яшьтән өлкәнрәк гражданнар һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасыннан тыш, 600 сум күләмендә риза булырсызмы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 31 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 21 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен - гражданнар җыенында 21 катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылы җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Сорау буенча карарны танырга: «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылы Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә сез, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш; Россия Федерациясе Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләре, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары; 85 яшьтән өлкәнрәк гражданнар һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасыннан тыш, 600 сум күләмендә риза булырсызмы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).» - кабул ителгән.

3. Зирекле авыл җирлеге Өргәнче авылы мәгълүмат стендында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итү, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә бастырып чыгару https://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Җ.Г. Гайфетдинов